СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за “Мамадышский”,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мира ур., 11А нче йорт, “Мамадыш” совхозы
поселогы, Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
“07” октября 2019 г.

Карар
№ 1- 46

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кызыл Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсе, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең “Референдум уздыру инициативасы турында” 2019 нчы елның 18 нче сентябрендә кабул ителгән 81 нче санлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2019 нчы елның 18 нче сентябрендә кабул ителгән 1-45 нчы санлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының 2015 нче елның 9 че гыйнварендә 3-19 нчы санлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кызыл Тау авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасын җыю һәм куллану турындагы Нигезләмәсе (2018 елның 17 нче сентябрендә кабул ителгән 5-35 нче санлы карары редакциясендә) нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кызыл Тау авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрүне 2019 нчы елның 24 нче ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган

гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-түбәндәге торак пунктларда ком һәм вак таш җәеп юллар төзекләндерү :
"Мамадыш" совхозы поселогы Көньяк урамы, Тукай урамы, Май тыкрыгы, Сәйдәшев урамы, Мәктәп урамы,
Красная Горка авылы Вахит урамы, М. Җәлил урамы,
Рус Пакшины авылы Яшьләр урамы, Дуслык урамы,
"Мамадыш" совхозының 2 нче фермасы поселогы Ленин урамы;

-түбәндәге торак пунктларда җирле әһәмияттәге юлларны тигезләү һәм кардан чистарту: "Мамадыш" совхозы поселогы, Красная Горка авылы, Максим Пүчинкәсе авылы, Ташлы авылы, Беляев Пүчинкәсе поселогы, "Мамадыш" совхозының 2 нче фермасы поселогы, Керәшен Пакшины авылы, Рус Пакшины поселогы;

- "Мамадыш" совхозы поселогы, Красная Горка авылы, Максим Пүчинкәсе авылы, Ташлы авылы,Беляев Пүчинкәсе поселогы, "Мамадыш" совхозының 2 нче фермасы поселогы, Керәшен Пакшины авылы, Рус Пакшины поселогы торак пунктларында урамнарны яктырту корылмаларына хезмәт күрсәтү (урам яктырткычларын төзек хәлдә тоту, сатып алу һәм яңага алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- Керәшен Пакшины авылы, "Мамадыш" совхозының 2 нче фермасы поселогы торак пунктларында су җыю башняларын койма белән әйләндереп алу;

- Керәшен Пакшины авылы, "Мамадыш" совхозының 2 нче фермасы поселогы торак пунктларында су алу скважиналарының павильоннарын төзекләндерү :

« ӘЙЕ » « ЮК »

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы В.Ә.Гыйззәтуллинага йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Советы рәисе /В.Ә. Гыйззәтуллина/